**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2025 елның 31 гыйнварындагы 197 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Идел буе районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 237 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры 16:50:171110:1491;

-урнашкан урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы;

- билгеләүнең максаты: газ белән тәэмин итү системасының линия объектларын һәм аларның аерылгысыз технологик өлешләрен урнаштыру («ТР ГРП-108 ТР, Казан шәһәре, 33 нче Хәрби шәһәрчек урамы, 2»);

- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләүгә нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» федераль законның 3.6 статьясы, Казан шәһәр Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре округының Генераль планы, «Газпром» гавами акционерлык җәмгыяте департаменты белән килештерелгән «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең 2022-2028 елларга исәпләнгән ЭПУ буенча бүлү газүткәргечләрне реконструкцияләү программасы, РФ Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы «Газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы

карары Федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында», Идел Буе районының Бердәм җитештерү-технологик комплексына милек хокукы теркәлгән (2001 елның 26 октябрендәге 16-50.3-23.2001-1053.1 номерлы).

2. Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдалану мөмкин булмаган яисә сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә шактый кыен булачак срок 3 ел тәшкил итә дип билгеләргә.

3. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Газпром Трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварындагы
197 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең Идел буе районында**
**ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:250
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |

| | |
|---|---|
| | гамәлдәге җир кишәрлекләренең чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:171110 | кадастр кварталы |
| 16:50:171110:1491 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |